ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАДРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАДРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2025 Кадрәк авылы № 19

«2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау " муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклауны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 11,13 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru), Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Михайлов А.А

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге
Башкарма комитетның
2025елның 8 декабрендә кабул ителгән
19 нче номерлы карары белән
расланды

# "2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасы

2025г.

**2026-2028 елларга**
**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының**
**Кадрәк авыл җирлеге территориясендә**
**җирләрдән файдалану һәм аларны саклау буенча муниципаль**
**программасының паспорты**

| | |
|---|---|
| **Программаны эшләү өчен нигез** | Россия Федерациясенең Җир кодексы, Россия Федерациясенең Бюджет Кодексы |
| **Заказчы** | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитеты |
| **Программаны төп эшләүче** | Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитеты |
| **Программаның төп максаты** | Кадрәк авыл җирлеге җирләрен саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану чараларын гамәлгә ашыру |
| **Программаны билгеләү** | Кадрәк авыл җирлеге җирләрен саклау мәсьәләләрен хәл итү |
| **Программаны гамәлгә ашыру вакыты** | 2026-2028 еллар |
| **Көтелгән нәтиҗәләр** | Җирләрне саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану, бозылган җирләрне торгызу, халыкның экологик иминлеген һәм аның тормыш сыйфатын арттыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру |
| **Программаны гамәлгә ашыруга контроль** | Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитеты, Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| **Программаны гамәлгә ашыру механизмы** | Җир биләүчеләрнең һәм алардан файдаланучыларның җирләрне саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану эшчәнлеген координацияләү Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла. Программаны төгәлләштерү кирәк булган саен үткәрелә |
| **Финансирование чыганагы** | Программаны үтәү муниципаль берәмлек бюджеты акчалары, оешмалар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла |
| **Финансирование күләме** | Авыл җирлеге бюджеты<br>2026 ел - 3000 сум.<br>2027 ел – 3000 сум.<br>2028 ел – 3000 сум |

**1.**

## 1. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өлкәсеннең хәзерге торышына характеристика һәм төп проблемалар.

Әйләнә-тирә мохитнең мөһим өлеше булган җирне куллану башка табигый объектлар - хайваннар, урманнар, үсемлекләр дөньясы, сулар, файдалы казылмалар һәм җир асты байлыклары белән бәйле. Җирдән файдаланмыйча һәм аны сакламыйча башка табигый ресурсларны куллану мөмкин түгел. Җиргә карата хуҗасызлык тиз арада яки якын киләчәктә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерәчәк, җирнең өске катламы - туфракның җимерелүенә, аның химик һәм радиоактив пычрануына гына түгел, ә бөтен табигый комплексга экологик начарлануга китерәчәк.

«2026-2028 елларга Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлегендә җирләрдән файдалану һәм саклау» муниципаль программасы (алга таба – Программа) икътисадны ныгыту файдасына дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итүче җирләрдән файдалану һәм саклау өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Җир фондын зур күләмдә төрле максатларда файдалану әйләнә-тирә мохитның барлык экосистема буыннарының табигый бөтенлеген саклау буенча билгеле бер йөкләмәләр сала. Табигатьтә барысы да үзара бәйләнгән. Шуңа күрә, экосистеманың берәр буынының дөрес эшләвен бозу, ул урман, хайваннар дөньясы, җир булсынмы, дисбалансга һәм экосистеманың бөтенлеген бозуга китерә.

Җирне рациональ кулланмау, аңа үз файдаңны гына күздә тотып һәм хуҗаларча булмаган караш җирнең башкара торган функцияләре бозылуга, табигый үзенчәлекләренең кимүенә китерә.

Җирне саклау нәкъ менә рациональ җир куллану тәэмин ителгәндә генә нәтиҗәле була ала.

Хәзерге этапта Девәтернә авыл җирлегендә тотрыклы социаль-икътисади үсеш һәм аның халкының экологик яктан куркынычсыз яшәеше проблемалары җирләрне саклау һәм куллану мәсьәләләрен хәл итү белән тыгыз бәйләнгән. Авыл җирлеге дәрәҗәсендә җирләрне саклау һәм куллану буенча җирле проблемаларны мөстәкыйль рәвештә, тулы, комплекслы һәм акыллы рәвештә чишү, хәзерге буын кешеләре өчен генә түгел, киләчәк буыннар файдасына да хәл итеп була.

Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге территориясендә төрлечә рөхсәт ителгән кулланылыштагы җир кишәрлекләре бар.

Авыл хуҗалыгына караган җирләр иң кыйммәтлеләре булып тора.

Авыл җирлеге территориясендәге көтүлекләр, культура-техник яктан караганда, күбесенчә чиста. Көтүлекләр шәхси ярдәмче хуҗалыклар тарафыннан файдаланыла.

Көтүлек азыгын кулланучыларның барысын да исәпкә алганда, табигый көтүлекләр артык авырлык кичерми. Торак пунктның күпчелек көтүлекләрендә яшел үлән артыгы белән. Территориянең экологик торышы уртача яхшы, әмма

рөхсәтсез, стихияле чүплекләр тирә-як мохиткә начар тәэсир итә һәм экологик хәлне тагын да катлауландыра.

## 2. Муниципаль программаның максатлары, бурычлары һәм максатчан күрсәткечләре, сроклары һәм тормышка ашыру этаплары.

Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлегенең законлылыгы һәм ачыклыгы, хисап бирүчәнлеге һәм контрольдә тотылуы, нәтиҗәлелеге җирлек территориясендә җирләрдән файдалану һәм саклау өлкәсендәге муниципаль сәясәтнең төп принциплары булып тора.

Муниципаль программаның максатлары - җирнең һәм туфракның пычрануын, кимүен, деградациясен, бозылуын, юкка чыгуын һәм җиргә, туфракка башка тискәре йогынтыны булдырмау һәм бетерү, шулай ук җирләрне рациональ файдалануны тәэмин итү, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең үзлекләрен яхшырту өчен, уңдырышлылыгын торгызу.

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

- җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекне оптимальләштерү;
- җирләрдән файдалану һәм саклау нәтиҗәлелеген арттыру, җирләрне рациональ файдалануны һәм саклауны оештыруны тәэмин итү;
- яшел үсентеләрне саклау һәм торгызу;
- җирләргә инвентаризация үткәрү.

Җирләрне инвентаризацияләү җирләрнең деградациясен, пычрануын, чүпләнүен, җимерелүен, хуҗалык эшчәнлегенең башка тискәре (зарарлы) йогынтысын булдырмау, файдаланылмый торган, рациональ файдаланылмый торган яки максатчан билгеләнеше буенча һәм рөхсәт ителгән файдалануга туры килми торган җир кишәрлекләрен, җирләрнең башка характеристикаларын ачыклау өчен үткәрелә.

Әлеге программаны гамәлгә ашыру җирдән файдалануны тәртипкә китерүгә, яңа җир кишәрлекләрен әйләнешкә кертүгә, авыл җирлегенең инвестиция җәлеп итүчәнлеген арттыруга, шуңа бәйле рәвештә икътисадның үсүенә, җирләрне нәтиҗәлерәк файдалануга һәм саклауга ярдәм итәчәк.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр тәэмин ителәчәк:

1). Торак пунктларны төзекләндерү;

2). Җирләрнең сыйфат характеристикаларын яхшырту;

3). Җирләрне нәтиҗәле файдалану.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2026-2028 еллар.

## 3. Муниципаль программаның төп чаралары исемлеге

Муниципаль программа кысаларында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклау һәм файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру буенча планлаштырылган чаралар.

| № | Чараның атамасы | Финансирование һәм аның (мең сумнарда) | Башкаручы | Үтәлү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Чокырларның өске сөзәклеген ныгыту | Оешмаларның, хосусый затларның, җирдән файдаланучыларның үз акчалары | Җирләрнең урнашу урыны буенча | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |
| 2 2. | Грунтның гомумтаралган файдалы казылмалар карьерларына инвентаризация үткәрү. Күрсәтелгән карьерларны конкрет оешмаларга беркетү. Аларны рекультивацияләү проектларын эшләү. | - | Авыл җирлеге башкарма комитеты | 2026-2028 | Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 3. | Карьерларны рекультивацияләү | Оешмаларның, хосусый затларның, җирдән файдаланучыларның үз акчалары | Карьердан файдаланучылар | даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Хосусый буаларны, башка гидротехник су объектларын ачыклау һәм бу корылмаларны конкрет милекчеләргә тапшыру. | - | Авыл җирлеге башкарма комитеты | 2026-2028 | Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 5. | Җирләрдән файдалану чикләрен, линия корылмалары объектларын, юл челтәрен, чикләнгән файдаланудагы җирләрне, сыйфат күрсәткечләрен куеп, әлеге җирләрнең бердәм банкын булдыру һәм алып бару | - | Авыл җирлеге башкарма комитеты | 2026-2028 | Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 6. | Девәтернә авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү | Авыл җирлеге бюджеты<br>2026 ел - 3000 сум.<br>2027 ел – 3000 сум<br>2028 ел – 3000 сум. | Авыл җирлеге башкарма комитеты | даими | Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 7. | Авыл хуҗалыгы җирләрен агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре белән капланудан саклау һәм зарарлы организмнардан яклау чараларын үткәрү | Җирдән файдаланучыларның үз акчалары | Җирләрнең урнашуы буенча | даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |
| 8. | Хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә деградациягә, пычрануга, чүпләнүгә, башка тискәре (зарарлы) йогынтылар аркасында бозылуга дучар булган җирләрне яхшыртуны һәм торгызуны тәэмин итү | Җирдән файдаланучыларның үз акчалары | Җирләрнең урнашу урыны буенча | даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |